# *МәүлидӘн-Нәбий мөбарәк булсын!*

Аллаһы Тәгаләгә барча мактаулар вә шөкерләр!
Безнең сөекле Пәйгамбәребез Мүхәммәдкә – Саләүәт!

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтте:

(وَ إِنَّكَ لَعَلى خُلُقٍ عَظِيمٍ) {سورة القلم 4}

Мәгънәсе: Аллаһы Тәгалә “Мүхәммәд Пәйгамбәрнең әхләгы бик күркәм вә матур”, – дип Коръәндә мактады.

***МӘҮЛИД*** – Мүхәммәд Пәйгамбәребезнең туган вакытын шатланып, бәйрәм рәвешендә үткәрелә торган җыелыш. Мәүлид Исләмда бик яхшы һәм изге гамәл. Мүхәммәд Пәйгамбәребез яшәгән вакытында Мәүлид Шәриф үткәрелмәгән. Ул – яхшы яңылык. Вә шул яңылыкны мәшрик белән мәгриб арасында яшәгән Исләм галимнәре хупладылар вә яхшы күрделәр. Аларның арасында: Әл-Хәфиз Әхмәд ибн Хәҗәр Әл-‘Аскаләний, Әл-Хәфиз Әс-Сәхауий, Әл-Хәфиз Әс-Суютый вә башка бик олыг галимнәр.

Әл-Хәфиз Әс-Сәхауий «Фәтәуи» исемле китабында шуны язган булган: “Мәүлид Шәриф Пәйгамбәребез вафат булганнан соң гына үткәрелә башлады. Һәм бу изге эш бөтен мөселман илләренә таралды. Мәүлид үткәрелгән вакытта ярлыларга садака бирәләр, Коръән укыйлар, Диний мәгълүмәтләрне аңлаталар, Пәйгамбәребезнең тарихын (сира) сөйлиләр. Шушы изге җыйылышлардан бәрәкәт алуны омтылалар.

«Раби‘ул-Әүүәл айында Мәүлид үткәрүне Шәригать рөхсәт итә ме? Бу гамәлдән сәвап була мы?» – дигән сорауларга Әл-Хәфиз Әс-Сүютый Мәүлид мәҗелесләрен уздыру турында «Мәүлид үткәрелгәндә ниятләрне дөресләү» мәкъалендә шулай диде: *«Мәүлид үткәрүнең төп максаты – кешеләрне җыеп, Коръән Сүрәләрен укыту, Пәйгамбәребезнең туган вакытында нинди вакыйгалар булганын сөйләп аңлату, килүчеләрне тәмле азыклар белән сыйлау. Мәүлид шулай үткәрелсә, бу эшне Шәригать хуплый, шул очракта мөселманнар аны уздырган өчен Сәвап казаналар, чөнки Мәүлид үткәрү – Мүхәммәд Пәйгамбәребезне олыглар өчен эшләнә һәм шуны белдерер өчен: Мәүлид – мөселманнар өчен бик шатлыклы».*

Мәүлид Шәрифне беренче булып уткәргән Ирбил илнең патшасы Музаффәр Әбу-Сәгид Кәүкәбрий ибн Зәй-нүд-Дин ‘Али ибн Бәктәкин. Ул һиҗрәт буенча VII гасырда яшәгән иде. Бу кеше үзе Шәригатне белеп үтәүче олыг галим булган. Каһарман булганы өчен аңа “Музаффәр” – “җиңүче” исемен кушканнар.

Ибн Әл-Җәүзи имамның оныгы “Заман көзгесе” дигән китабында шуны сөйли: Мәүлид үткәргән вакытта бик олыг Исләм галимнәре шул мәҗелесләргә килгән иделәр. Шулай ук Мәүлид уздырганда янына хәдисләрне яхшы белүче изге суфыйлар килеп, хөрмәтләрен күрсәтә иделәр. Ибн Кәсир «Башлану һәм бетү» атлы китабында Музаффәр патша турында шулай әйткән: “ул һәр Раби‘ул-Әүвәл айында Мәүлид үткәрер өчен бик зур мәҗелесләр җыйган булган. Музаффәр бик тугры кеше һәм гадел патша булган”.

Ибн Кәсир әйткән: “шейх Әбүл-Хаттаб ибн Дихья – Музаффәр патшага «Әт-тәнүир фи Мәүлид әл-бәширән-нәзир» дигән Мәүлид китабын язган. Шул китабын язган өчен Музаффәр патша – шейх Әбүл-Хаттаб ибн Дихьяга 1000 динар бүләк итте вә шул Мәүлид китабын укырга рөхсәт бирде. Музаффәр патша ‘Аккә шәһәрендә һижри 630 елда мөселманнарны “крестовый поход” вакытында кәферләрдән коткарган.

Шуңа күрә без бер шиксез әйтәбез: Мәүлид бәйрәмен үткәрү – Шәригаттә кабул булган яхшы яңылык, бу эшне инкәр итү һич дөрес түгел. Киресенчә, аны – “сөннәт” дип атарга ярый. Чөнки Пәйгамбәребез үзе әйтте:

”مَنْ سَنَّ فِي الإسْلام سُنَّةً حَسَنَةً فَلَهُ أَجْرُهَا وَأَجْرُ مَنْ عَمِلَ بها بَعْدَهُ مِنْ غَيْرِ أَنْ يَنْقُصَ مِنْ أُجُورِهِمْ شَىْء، وَمَنْ سَنَّ في الإسْلاَمِ سُنَّةً سَيِّئَةً كَانَ عَلَيْهِ وِزْرُهَا وَوِزْرُ مَنْ عَمِلَ بها مِنْ بَعْدِهِ مِنْ غَيْرِ أَنْ يَنْقُصَ مِنْ أَوْزَارِهِمْ شَىْء“.

Мәгънәсе: кем Исләм диненә яхшы (Коръәнгә вә хәдисләргә мүәфик булган, дингә каршы килмәгән) яңылык керткән булса – шул гамәл өчен сәвап алыр, вә һәркем шушы яхшы яңылыкны дәвам итсә сәвап алыр, вә ул кешеләрнең сәвабы азаймыча башлаучыга да булыр. Әмма кем Исләм диненә яман (Коръәнгә вә хәдисләргә каршы булган) яңылык керткән булса – шул гамәл өчен гөнаһ алыр, вә һәркем шушы яман яңылыкны дәвам итсә – гөнаһ алыр, вә ул кешеләрнең барча гөнаһлары кадәр азаймыча башлаучыга да булыр.

## *Пәйгамбәребезнең нәсәб шәрифе*

Мүхәммәд Пәйгамбәребезнең әтисе – ‘Абдуллаһ, бабасы – ‘Абдуль-Мутталиб, икенче бабасы Һәшим, өченче бабасы – ‘Абду-Мәнәф, һәм беләбез: Пәйгамбәребез – Курайш кабиләсеннән. Аның нәселе – Ибраһим Пәйгамбәрнең улы – Исмәгыйл Пәйгамбәргә тоташа. Аллаһы Тәгалә Мүхәммәд Пәйгамбәребезнең нәселен зина кылу сәбәбе белән туудан саклады. Аның пак нәселендә һичбересе зинадан тумаган.

‘Абдуллаһ – Пәйгамбәребезнең әтисе Зуһра кабиләнең Ваһб кызы Әминә исемле хатынга өйләнде. Ваһб кызы Әминә Пәйгамбәребезгә әни булып сайланды.

Әминә ханумның хәмилә вакытында һич авырлык сизмиче хөрмәтле йөген йөретте вә күп гаҗәеп нәрсәләр булды: фәрештәләрнең аның янында тәсбих әйтүләрен ишеткән икән. Кошлар Пәйгамбәребезне хөрмәтләп Әминәнең башы өстендә әйләнеп очып йөрегәннәр. Вә тирән кое янына су алыр өчен килсә – Пәйгамбәребезне олыглап кое суы Аллаһының рәхмәте белән тирән коеның төбеннән читенә кадәр менгән икән.

Аллаһы Тәгалә Үз рахмәте белән Мүхәммәд Пәйгамбәребезне гарәпләр вә башка халыклар арасында иң өстен кылды.

Ул – барча галәмдә булган мәхлүкатьләрнең иң шәрәфлесе!

Пәйгамбәребезнең дөняга килер вакыты якынлашты. Корып беткән җирләр, корыган үсемлекләр һәм ашлыклар яңгырлар белән суланып, яшелләнеп, гөрелдәп, чәчәкләр атып үсә башладылар.

Хөрмәтле Пәйгамбәребезнең туган вакытын барчасы көттеләр. Ул туган вакыты – чүлләр һәм шәһәрләрдә яшәүчеләр өчен, күчеп йөрүче халыклар вә бер урында гына урнашкан халыклар өчен яктылык килүе турында шатлыклы хәбәр иде. Бөтен дөньяда, җир вә күкләрдә Пәйгамбәребезнең тууы турында сөйләделәр.

Пәйгамбәребез Мүхәммәд салләллаһу ‘аләйһи үә сәлләм якты дөньяга тәне һәм жаны белән килгән. Ул – фил елы, Рабигыль-Әүвәл айында туды, туган көне – 12-че көн, дүшәмбе иде.

Әминә ханум белән ‘Абдуллаһның бер генә балалары булган – Мүхәммәд Пәйгамбәребез, вә аларның бүтән бала булмаган.

### *Мәүлид китапларында йыш очырый торган хаталар*

Коръәндә вә хәдисләрдә Пәйгамбәребезнең бөек дәрәҗәсе вә изгелеге турында, мөселманнарның Пәйгамбәребезне олыглау турында күп әйтелгән. Шуңа күрә, ялган хәбәрләрне күз алдына китереп, аларга таянып Коръәндә вә хәдисләрдә Пәйгамбәребез турында мактауларга вә олыглауларга берни өстәп, кушып я дә киметеп әйтергә ярамый.

Имам Әхмәд вә имам Ибн Хиббән – II Халиф ‘Умәрдан Пәйгамбәребезнең хәдисен риваять иттеләр: *“христианнар ‘Иса Пәйгамбәрне ялгышып бик зурайтып мактаган кебек Мине олыгламагыз. Мин Аллаһның колы һәм Пәйгамбәре”*.

Мүхәммәд Пәйгамбәребез әйтмәгән сүзләргә – «Пәйгамбәрнең сүзе ул», дию – бик зур гөнаһ. Андый алдау бик начар вә зарарлы. Имам Әл-Бухарий вә Мүслим Пәйгамбәребезнең шушы хәдисен риваять иттеләр, аның мәгънәсе: *«Кем минем исемемнән мин сөйләмәгән сүзләрне әйтеп, алдаса – шул кеше ялганчыларның береседер. Кем минем исемемнән ялган сөйләсә, шуңа Җәһәннәмдә урыны әзердер»*.

Кешеләрнең кулларына ялгыш мәгълүмәтләр белән кайсыбер китаплар эләккән. Шул китапларда Аллаһы Тәгаләне яратылган нәрсәләр белән чагыштыралар, Аллаһыга кимчелекле сыйфатлар кушалар, я дә Аллаһы Тәгаләгә генә хас булган сыйфатларны мәхлүкъатьләрдә дә бар диләр.

Шуңа охшаган китапларны бер кайчан да укырга ярамый. Мәүлид рәвешендә язылган булса да, башка китап кебек булса да, барыбер ул китаплар бик зыянлы! Андый яман нәрсәләрне эшләргә ярамаганы турында мөселманнар бер бересенә һәр вакыт әйтергә тиешләр.

Шулай Мәүлид турында гарәп халыгы арасында бик таралган «мәулид аль-гарус» исемле китап бар. Шул китапта Пәйгамбәребез хаккында күп ялган хәбәрләр язылган. Мәсәлән: имеш Аллаһ йөзеннән бер уч нур алып, селтәгән һәм әйткән имеш: «Мүхәммәд бул!» вә шулай Мүхәммәд Пәйгамбәребез яралтылган имеш.

Аллаһ турында шулай әйтү – Диннән чыгара, көферлек була. Кушылу-берләшү, айырылу-бүленү, килү-китү, заһир булу-югалу Аллаһыга ләек түгел котгый рәвештә.

Аллаһыга шуның кебек нәрсәләрне кушарга ярамый: тән, гәүдә, йөз-бит, кул-аяк, тел, авыз, әгъзә, сан, санау, микдар, күбәю, азаю кебек. Аллаһ андый нәрсәләрдән өстен вә пакъ. Аллаһы Тәгаләгә бер нәрсә дә охшамаган. Шул турыда Коръәндә әйтелгән:

(لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَىْءٌ وَهُوَ السَّمِيعُ البَصِيرُ) {سورة الشورى 11}

*«Аллаһы Тәгаләнең охшашы юк. Ул һәр нәрсәне ишетә вә һәр нәрсәне күрә» (әмма күз вә колак белән түгел).*

Кем Мүхәммәд Пәйгамбәрне, я дә башка берәр мәхлүкне – «Аллаһның өлеше», – дисә, мөселман түгел! Исләм динендә түгел.

Аллаһның охшашы юк, Аллаһ бар, әмма җисемсез, тәнсез, Аллаһ бүленми. Ләкин «мәүлид әл-гарус» китабында киресенчә язылган.

Кайсыбер кешеләр шундый яңлыш фикер тараталар: Пәйгамбәребез – бөтен кешеләрнең беренчесе булып яралтылган, – дияләр. Бу хәбәр – хәдистән, диеп ялган сөйлиләр. Хәтта кайсыбер мөәззинәр бу нохак сүзләрне Азан укыганда кушалар. Асылда андый хәдис юк. Пәйгамбәребез беркайчан да: «мин – Аллаһның беренче яралтылган бәндәсе», – дип әйтмәгән. Шул вә охшаш сүзләр – ялган. Аңа: «Пәйгамбәр әйтте», дию – үзе тагын да бер ялган. Андый сүзләр Коръәнгә вә Сөннәткә каршы!

Коръән-и Кәримнән дәлил:

(وَجَعَلْنَا مِنَ الْمَاءِ كُلَّ شَىْءٍ حَيٍّ)

*“Барча тере нәрсәләр судан яралтылган”* (21:30).

Коръәндә Пәйгамбәребез турында әйтелгән:

(قُلْ إِنَّمَا أَنَا بَشَرٌ مِّثْلُكُمْ يُوحَى إِلَيَّ أَنَّمَا إِلَهُكُمْ إِلَهٌ وَاحِدٌ)

*”Әйт: мин сезгә охшаган кешемен, миңа вахий иңдерелгән – Аллаһ Бер булганы турында”* (41:6).

Әл-Бухарий вә Әл-Байһакый имамнар ‘Умран ибн Хүсәйннән Пәйгамбәребезнең хәдисен риваять иттеләр:

«كَانَ اللهُ وَ لم يَكُنْ شَيْءٌ غَيْرُهُ وَ كَانَ عَرْشُهُ عَلَى الماءِ»

*“Аллаһ әүвәлсез мәңге булган, Аллаһтан башка берни юк иде. Беренче булып – су яралтылган, судан – Әл-‘Арш яралтылган”.*

Ибн Хиббан риваять иткән хәдистә Әбу Һүрайраһ әйткән булган: Пәйгамбәребездән: “барча нәрсәләр кайчан һәм ничек яралтылганнар?” – дип сораганда, Пәйгамбәребез: “бөтен нәрсәләр судан яралтылган”, – диеп җәвап биргән.

Әс-Сүддий риваять иткән бер хәдистә Пәйгамбәребез шулай әйткән: «Аллаһы Тәгалә судан элек берни яралтмады».

Исбатсыз вә дәлилсез әйтелгән ялган әкиятләрдән кайсыберләрен әйтеп китиек:

**1.** «Мин беренче булып яралтылдым һәм соңгы Пәйгамбәр булып килдем!» – диелгән яңылыш сүз.

**2.** «Адәм яралтылганнан элек, Мин инде Пәйгамбәр булган идем», – ялгышып әйтәләр.

**3.** «Әле Адәм дә юк иде, су да юк иде, мәте (туфрак) да юк иде. Ә Мин инде Пәйгамбәр булган идем», – диеп алдыйлар.

**4.** «Пәйгамбәр булмаса иде, Аллаһы Тәгалә галәмне яралтмас иде», – диелгән тагын бер ялган фикер.

**5.** «Җәбраил фәрештә бер пәрдә аша вахий алган, имеш, аннан соң шул вахийне Мүхәммәд Пәйгамбәргә тапшырган. Вә соңра шул пәрдә төшкәч, Җәбраил Фәрештә анда Мүхәммәд Пәйгамбәребезне күргән, имеш.

Җәбраил әйткән булган имеш: «Синнән – Сиңа ук кире тапшырам?!!» – бу да Коръәнгә каршы булган бик ачык ялган.

**6.** «Пәйгамбәребез Мөхәммәд ‘аләйһиссәләм Җәбраил фәрештәдән сораган, имеш: «Син инде дөньяда күпме торасың?», – диеп; шуңа Җәбраил җавап биргән имеш: «күпме яшәгәнемне белмим, вә ләкин белгәнем шул: 70 мең ел дәверендә бер тапкыр гына күренә торган йолдыз бар, шушы йолдызны мин инде 72 мең мәртәбә күрдем». Пәйгамбәребез аңа җавап биргән имеш: «Аллаһ белән ант итәм, ул йолдыз – мин идем». Бу бик зур ялган вә нохак**.**

Бу сүзләр ялгыш, хәдис түгел! Шуңа күрә аларны аңлатырга да кирәге юк.

Сүзләрнең ахырында игьтибар итәбез шуңа:

Соңгы 200 ел эчендә мөселманнарның Хиҗәз җирләрендә, Нәжд өлкәсендә бер яман агым килеп чыкты. Бу фирка Мәүлид үткәрүне яхшы күрмиләр, каршы чыгып: «ярамый» – диләр. Һәм алар Шәригаттә дөрес булган бөтен яңылыкларны инкәр итеп, шул эшләрне тыялар. “Пәйгамбәр яшәгән вакытында эшләнмәгән – әле дә кирәкми”, – диләр. Бөтен яңылыкларны – “адаштыручы”, – диләр. Әмма үзләре яман яңылык!

Бу фирка шулай ук Тәүәссүлне инкәр итәләр. Тәүәссүл – Пәйгамбәр аркылы (Аның хөрмәтенә) Аллаһыга ялвару, дога кылу, бәрәкәтен теләп сорау.

Шушы мәглүмәтләрне күз алдына китереп алганнан соң ошбу нәтиҗә килеп чыга: вәһһәбиләрнең фиркасы – хак юлдан бик ерак киткән, Ислә Динебездән чыгып киткән. Вәһһәбиләр – адашкан кешеләр, алар Дин дошманнары.

Күп төрле адашкан фиркалар бар, игтибар итегез, аларның зарарларыннан сак булыгыз, алар өйрәткән мәгълүмәтләрне кабул итмәгез, алар әйткән сүзләренә ышанмагыз. Чөнки алар ни сөйләсәләр дә – үз агулы фикерләрен чәчергә туктамыйлар!!!

***Аллаһы Тәгалә изге гамәлләребезне кабул итсен һәм мәдәд бирсен вә бу фани дөньядан мөселман булып чыгуны нәсыйп итсен! Иманыбыздан аермасын!***

***Аллаһы Тәгалә безгә дә, сезгә дә Мөхәммәд Пәйгамбәребезнең шәфәгатен нәсыйп итсен!***

***Мәүлид Шәрифне дөрес үткәрергә һәм бу эштән күп сәвап алырга Аллаһ җиңел итсен!***

***Аллаһы Тәгаләгә мактау-шөкерләр булсын!***

***Мөхәммәд Пәйгамбәребезгә – иң матур Саләүәт!***

***Изге теләкләр белән –***

***Украина мөселманнары Диния идарәсе***
***04071, г. Киев, ул. Лукъяновская, 46,***
***тел. (044)465-18-77, 465-18-78, факс 456-17-70***
***E-mail: islam@i.kiev.ua, www.islamyat.org***

*Украина мөселманнары Диния идарәсе*

# *МӘҮЛИД*

# *ӘН-НӘБИЙ*

*татар телендә*

*Киев – 2007*